ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.10.2025 г. Заинск № 480

**2026 елга «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең нәфис-эстетик юнәлештәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 14 декабрендәге 854 номерлы «Татарстан Республикасында нәфис-эстетик юнәлештәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф учреждениеләрен норматив финанслауны кертү турында» карары нигезендә һәм Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. 2026 елга расларга:

«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең нәфис-эстетик юнәлештәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә кушымта итеп бирелә торган норматив чыгымнар;

сәнгать-эстетик юнәлештәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарга 0,85 күләмендә төзәтмә коэффициенты.

2. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларын әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнар нигезендә финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» нда түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Валиахметова М.К.
9-90-16

«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карары белән расланды
«15» 10 2025 елдан № 480

«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы»муниципаль берәмлегенең нәфис-эстетик юнәлештәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә

НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлеше | Территориаль дислокация | Норматив чыгымнар, бер укучыга елына сум | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | өч еллык уку срогы | дүрт еллык уку срогы | биш еллык уку срогы | җиде еллык уку срогы | сигез еллык уку срогы | иртә һөнәри ориентация |
| Музыка сәнгате | шәһәр җирлеге | 99 826 | 95 524 | 96 798 | 111 416 | 115 995 | 150 794 |
| Музыка сәнгате | авыл җирлеге | 104 247 | 99 756 | 101 088 | 116 348 | 118 295 | 157 454 |
| Сынлы сәнгать | шәһәр җирлеге | | 49 900 | 42 477 | 39 295 | 43 367 | 99 300 |
| Сынлы сәнгать | авыл җирлеге | | 52 078 | 44 324 | 41 001 | 45 254 | 103 657 |
| Хореография сәнгате | шәһәр җирлеге | | | 97 308 | 79 435 | 84 263 | 342 950 |
| Хореография сәнгате | авыл җирлеге | | | 101 666 | 82 983 | 85 697 | 358 407 |
| Гомуми эстетик сәнгать | шәһәр җирлеге | | | 43 534 | | | |
| Гомуми эстетик сәнгать | авыл җирлеге | | | 45 469 | | | |
| Фольклор сәнгате | шәһәр җирлеге | | | 101 217 | 97 465 | 100 551 | 165 858 |
| Фольклор сәнгате | авыл җирлеге | | | 105 731 | 101 809 | 102 618 | 173 253 |
| Эстрада-джаз сәнгате | шәһәр җирлеге | 156 530 | | 151 191 | | | 263 997 |
| Эстрада-джаз сәнгате | авыл җирлеге | 171 693 | | 157 939 | | | 275 771 |
| Театр сәнгате | шәһәр җирлеге | 77 614 | 70 087 | 72 585 | 72 557 | 76 069 | 107 794 |
| Театр сәнгате | авыл җирлеге | 81 056 | 73 192 | 75 802 | 75 771 | 77 485 | 112 534 |